ULUSLARARASI TÜRK LEHÇE ARAŞTIRMALARI DERGİSİ (TÜRKLAD), 2. CİLT, 1. SAYI, 2018, 163 - 173. s., TÜRKİYE

# РОБЕРТ МИННУЛЛИН ИҖАТЫ: БАЛАЛАР ӨЧЕН ТӘРҖЕМӘЛӘРДӘ ИҖАДИ ИҖАТ КУӘСЕНЕҢ ЧАГЫЛЫШЫ

*Liailia MİNGAZOVA**

**Аннотация**

Хезмәтнең тикшеренү обекты булып, ТР халык шагыйре, ТР Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Г.-Х.Андерсен исемендәге Почетлы диплом иясе Роберт Миңнуллинның тәрҗемәләре тора. Рус, каракалпак, төрекмән, мари, чуаш, грузин, әрмән, казакъ, удмурт, литва кебек милләт шагыйрьләренең әсәрләре аның тәрҗемәсендә татар укучысына да якын.

Мәгълүм ки, гасырлар дәвамында милли идеаллар, әхлакь принцилары аша милли әдәбиятлар формалаша. Төрле тарихи этапларда, географик шартлар белән дә бәйле, миллилек, гореф-гадәтләр, традицияләр кебек төшенчәләр ярдәмендә балалар күңеленә тәэсир итәрдәй нигезле психологик алымнар, чаралар туа һәм алар яшь буында милли үзаң формалашуда нигез булып тора. Р. Миңнуллинның уңышлы тәрҗемәләре аша балачак иле, сабыйларның дөньяны танып белүе, төрле милләт балаларының уйлары һәм теләкләре бердәй дәрәҗәдә охшаш һәм тәңгәл икәнлеге отышлы ачыла. Ягъни, Р. Миңнуллин тәрҗемә эшчәнлегендә телнең бөтен эчке мөмкинлекләреннән дә файдаланып эш итә.

**Төп Төшенчәләр:** Татар Балалар Әдәбияты Тарихы, Милли Әдәбиятләр, Роберт Миңнуллин, Тәрҗемәләр, Төрки халыклар поэзиясе.

# ROBERT MİÑNULLİN'İN SANATI: ÇOÇUKLAR İÇİN YAPTIĞI ŞİİR ÇEVİRİLERİNDE YARATICILIK YETENEĞİNİN GÖRÜNÜMÜ

**Özet**

Bu makalede Tataristan Cumhuriyeti halk şairi, Tataristan Cumhuriyeti Abdullah Tukay Devlet Ödülü, H. C. Andersen Onur Ödülü sahibi Robert Miñnullin'in başka dillerden çevirdiği şiirler konu edilmektedir. Robert Miñnullin'in Rusça, Marice, Udmurtça, Ermenice, Gürcüce, Litvanca gibi dillerden ve Karakalpak, Türkmen, Kazak gibi Türk lehçelerinden yaptığı çeviriler Tatar okuyucusu tarafından yakından bilinmektedir.

Bilindiği üzere, asırlar devamında millî ülküler, ahlak prensipleri vasıtasıyla millî edebiyatlar şekillenir. Çeşitli tarihî etaplarda, coğrafi şartlara da bağlı olarak millîlik, örf-âdetler, gelenekler gibi düşünceler yardımıyla çocukların gönlüne tesir edercesine sağlam psikolojik etkenler, çareler doğar ve onlar genç nesilde millî bilincin oluşmasında temel oluşturur. R. Miñnullin'in başarılı tercümeleri sayesinde çocukların dünyayı tanıması, çeşitli milletlere mensup çocukların düşünce ve dileklerinin hemen hemen benzer ve aynı olduğu sonucu ortaya çıkar. Kısacası, R. Miñnullin tercüme yaparken dilin bütün iç imkânlarından faydalanmıştır.

**Anahtar Kelimeler:** Tatar Çocuk Edebiyatı, Millî Edebiyat, Robert Miñnullin, tercüme, Türk halk şiiri

* Prof. Dr., Kazan Federal Üniversitesi, Kazan / TATARISTAN – RUSYA, el - mek: leila69@inbox.ru

ORCİD ID: https://orcid.org/0000-0001-5116-1419

# ROBERT MINNULLIN: HIS IMAGE IN HIS TRANSLATION FOR CHILDREN

**Abstract**

The object of the study is R. Minnullin's literary translation: a review of the Tatar translation of poems dedicated to children, from the poetic heritage of different nations: Russian, Karakalpak, Turkmen, Georgian, Armenian, Kazakh, Lithuanian, Moldovan, Ossetian, Mari, Chuvash, Udmurt and others.

Whereas the literary text represents the subjective picture of the world, a mental model, based on interpreter's individual reading the symbols of the translated works, is used as a method of world interpretation. A comparative analysis of the literary text and its translation into the Tatar language allows detecting the level of poet's translation competence in the field of showing symbolic meaning.

The article also discusses the translation difficulties caused by the mismatch of grammatical categories in different languages. The authors give the examples of literary texts, in which grammatical categories are semantic means.

**Key Words:** Tatar Child Literature, National Literature, Robert Miñnullin, translation, Turkish folk poetry

XX-XXI гасырлар чигендә тәрҗемәләрнең тарихи-теоретик тәҗрибәсен гомумиләштерү, мәгълүм ки, идеологик критерийлардан азат булган яңа шартларда бара. Яңа тикшеренүләрне анализлау тәрҗемә тәгълиматы мәсьәләләренең алгы сызыкка чыгуын һәм бу фәнни эшчәнлек өлкәсенә төрле тармактагы күпсанлы галимнар мөрәҗәгать итүен күрсәтә.

Тәрҗемә әсәрләре, нинди булуга карамастан, төрле милләт халыкларының рухи хәзинәләр алмашуына, аралашуына, яңа мәгълүматлар туплавына хезмәт итә. Нәкъ менә шуңа күрә, тел, әдәбият тарихы, аның бүгенге торышы белән бәйле актуаль мәсьәләләр соңгы дистә еллар тарих, лингвистика, психология белән бәйле тикшеренүләрнең үзәгендә тора.

Әмма, ничек кенә булмасын, башка милли характерларны, яшәешне, үзгә рухи дөньяны аңлау һәм, иң әһәмиятлесе, шул үзенчәлекләрне үз телеңдә тасвирлау өчен камил чаралар таба белү таланты һәркемгә бирелмәгән. Тарихи-мәдәни контекстан тыш, тәрҗемәчегә төрле милләт язучыларының дөньяны танып белүе һәм тел үзенчәлекләрен, стилен сиземләве дә кирәк, нәкъ менә әлеге тоемлау тәрҗемә әсәренең тормышчан яңгырашын тәэмин ителәә. Аерым язмалардан күренгәнчә, Р. Миңнуллин тәрҗемәдә, шәхсән үзе таныш булган авторлар иҗатына ныграк басым ясый.

Л.С. Бархударов фикеренчә, тәрҗемәнең максаты - төрле телдә аралашкан кешеләр арасында сөйләм элемтәсе булдыру [Бархударов 1075:14]. Мондый крашта хаклык зур. Хәзерге вакытта тәрҗемә юнәлешендә эшләүче галим-тикшеренүчеләр тәрҗемә процессын, еш кына, телара аралашу акты буларак сыйфатлаган теоретик модельләрдә карыйлар. Мисал өчен, Е.В. Бреус [Бреус, 2002], F.G. Galimullin [Galimullin, 2014], Р.А. Юсупов [Юсупов, 1975], Хабутдинова [Хабутдинова, 2017] хезмәтләрен китерергэ момкин.

Шуның белән бергә, әдәби тәрҗемә башка төр тәрҗемәләрдән байтак дәрәҗәдә аерыла. Тәрҗемә теориясе юнәлешендә эшләүче галим В.Н. Комиссаров фикеренчә, «Матур әдәбият әсәрләрендә әдәби-эстетик, яисә коммуникатив максат-вазыйфа әйдәп баручы ролен үти. Эстетик юнәлешнең мондый төре әдәби сөйләмне мәгълүмати эчтәлеге беренчел, мөстәкыйль булган башка сөйләм коммуникациясе төрләреннән аерылып тора» [Комиссаров, 190:95].

Тәрҗемә тарихы өйрәнгән галим Е.В. Бреус фикеренә таянсак, бу юнәлешне тагын да киңрәк планда алып карау мәҗбүри: «Тәрҗемә барышында тел формалары гына чагыштырылмый, бәлки, дөньяны күрү һәм аралашу хәлләре белән берлектә гомуми мәдәният төшенчәсе белән билгеләнгән телгә кагылышсыз факторлар да карала» [Бреус, 2002:25].

Бүгенге көндә татар әдәбиятында тәрҗемә зур урын тота һәм ул милли әдәбиятның зур бер өлешен тәшкил итә.

Тарихка беркадәр күзәтү эшләп үтсәк, татар телендә тәрҗемә әсәрләренең күбесе рус әдәбиятыннан алынган әсәрләр. Аның беренче үрнәкләре М. Иванов төзегән «Татар әдәбияты хрестоматиясе»ндә (1842) китерелә. Рус авторларыннан, аеруча А. Пушкин, М. Горький, Н. Островский, В. Короленко кебек язучыларның әсәрләре татарчага күпләп тәрҗемә ителә, һәм, укучылар арасында киң яңгыраш таба.

Алга таба, XIX гасырның икенче яртысында, рус һәм Көнбатыш Европа, гарәп-фарсы әдипләренең әсәрләренә һәм педагогикасына мөрәҗәгать итү нәтиҗәсендә, соңгыларының татар балалар әдәбиятына йогынтысы сизелә башлый. «Мең дә бер кичә», «Кәлилә вә Димнә» әсәрләре тәрҗемә ителә. Ул чорда рус һәм гарәп-фарсы телләрен, әдәбиятын яхшы белгән, Көнчыгыш традицияләре рухында педагогик идеяләрне, акыл бирердәй хәл-әхвәлләрне тасвир иткән зур галим Каюм Насыйри (1825 – 1902) яши һәм иҗат итә.

К. Насыйриның «Әбүгалисина кыйссасы», «Гөлрөх һәм Кәмәрҗан әкиятләре», «Кырык вәзир кыйссасы» кебек әсәрләр бүгенге көндә дә әһәмиятләрен югалтмадылар. Шулар арасыннан «Әбүгалисина кыйссасы» – иң танылган әсәрләренең берсе. Төрек язучысы Зыятдин Сәеднең «Кәнҗинән хикмәт» исемле әлеге әсәрен К. Насыйри 1972 елда тәрҗемә итеп, эшкәртеп, «Әбүгалисина кыйссасы» исеме астында бастыра.

К. Насыйриның әлеге әсәрне тәрҗемә итәргә алынуы очраклы хәл булмый. Чөнки биредә күтәрелгән төп тема, идея-фикерләр аның тоткан мәсләге, кыйбласы белән туры килә. Мәгърифәтче галим буларак, гомере буе үзе дә аң-белемгә омтылган әдип әлеге әсәр ярдәмендә белемнең зурлыгына, олылыгына мәдхия җырлый, белемле кешенең өстенлеген күрсәтергә тели.

XX гасыр башында тәрҗемә эше тагын да җәелеп китә. Рус, француз, инглиз, немец әдәбиятыннан үрнәкләр, шулай ук, Н. Гоголь, А. Пушкин, Л. Толстой, М. Горький, Д. Мамин-Сибиряк, И. Тургенев, А. Куприн әсәрләре И. Богданов, Д. Гобәйди, С. Сүнчәләй, Н. Хәлфин һәм башкалар тәрҗемәсендә дөнья күрә. Ф. Сәйфи Казанлы, С. Рахманкулов, С. Җәләл кебек тәрҗемәчеләр чит ил язучыларыннан Х. Андерсен, В. Гауфф, О. Уайльд, В. Гюго, Р. Киплинг, урыслардан Л. Толстойны бик яратып тәрҗемә итәләр. Мондый эшчәнлекнең нәтиҗәсе дә куанычлы. Чөнки тәрҗемә әсәрләләре «татар әдәбиятына жанр, форма төрлелеген алып килә, тематик эзләнүләр мәйданын киңәйтә, психологик анализ көчәюгә, әдәби стильләрнең үзләштерелүенә китерә» [**Заһидуллина, 2000**:100].

XX гасыр татар балалар поэзиясе юнәлешендә бу өлкәдә әйдәп баручы талантларның берсе, әлбәттә, Габдулла Тукай. Аның тәрҗемә тәҗрибәсе үз вакытында һәм хәзер дә югары бәяләнә. Чөнки ул төрле халыклардан иң уңышлы әсәрләрне татар рухына, татар мөхитенә якын рәвештә тәрҗемә итә алды. Шагыйрьнең «Бала белән Күбәләк» (Л.Н. Модзалевский, «Мотылек»), «Таян Аллага» (И.С. Никитин, «Молитва дитя»), «Баскыч» (А.Е. Измайлов, «Лестница»), «Яхшы хәбәрләр» (А.Н. Плещеев, «Капля дождевая»), «Яңгыр» (А.Н. Майков, «Летний дождь»), «Карлыгач» (И.С. Никитин, «Гнездо ласточки») һ.б. шигырьләре, күп сандагы мәсәлләре иректе тәрҗемә ителгән. Биредә Г. Тукайның шагыйрьлеге дә, оста тәрҗемәче булуы да ачыла. Чөнки шигырьләр

татар дөньясына, татар әдәбиятына хас детальләр белән, милли аһәң белән сугарылган һәм иң мөһиме – югары сәнгать дәрәҗәсендә.

Балалар поэзиясе үсешенә үзеннән зур өлеш керткән һәм балалар әдәбиятының югары баскычында торучы шагыйрь Р. Миңнуллинның тәрҗемәләре хакында да «уңышлы», «югары кимәлдә» фикерләрен курыкмыйча кулланырга мөмкин. Чөнки ул соңгы берничә дистә ел эчендә талантлы тәрҗемәче буларак та ачылган, татар балалар әдәбиятын кызыклы, мәгънәле шигырьләр белән дә баеткан шәхес. Шагыйрь И. Юзеев сүзләре белән әйтсәк: «... Р. Миңнуллинны үз халкының язмышы, гореф-гадәтләре, йолалары кызыксындыра. Әмма шагыйрь үз казанында гына кайнаса, аның офыгы тараер иде. Роберт моны аңлап, тугандаш халыкларның тормышын да өйрәнергә тырыша» [Юзеев, 1978:186].

Р. Миңнуллин тәрҗемәсендә рус, каракалпак, төрекмән, мари, чуаш, грузин, әрмән, казакъ, удмурт, литва һ.б. халык шагыйрьләренең әсәрләре татар укучысына да якын: руслардан Агния Барто, Сергей Михалков, Михаил Яснов, Геннадий Паушкин; удмуртлардан Владимир Романов; марилардан Анатлий Тимиркаев; чуашлардан Раиса Сарби, Василий Давыдов-Анатри; латыштан Ояр Вациетис, Леон Бриедис; молдаваннардан Виеру Григоре; литва Юозас Некрошюс; каракалпак язучыларыннан Жолдас Сәетназаров; казахлардан Мозаффар Әлимбаев; төрекмәннәрдән Каюм Тәңрекулиев, Агагельды Алланазаров; әрмән язучыларыннан Сильва Капутикян; гөрҗиләрдән Нодар Думбадзе һ.б., халык шагыйре тарафыннан, яратып тәрҗемә ителгән авторлар исемлегендә. Аларның һәрберсе – талантлылар сафында. Һичшиксез, киңкүпчелеккә мәгълүм мондый авторларның шигырьләрен татар укучысына тәкъдим итеп, Р. Миңнуллин татар балалар әдәбиятының тәрҗемә әсәрләре хисабына баюына зур өлеш кертә. Моны шагыйрь үзе дә аңлый һәм татар балаларын башка милләт балалар язучылары, аларның иҗат җимешләре белән таныштыруны бурычы итеп саный. Әлеге өлкә турында уйланып, «Дөньяның төрле кыйтгаларында балалар шагыйрьләре яши. Ул шагыйрьләрнең илләре генә, туган җирләре генә, исемнәре генә төрледән-төрле, ә менә шигырьләре, геройлары, аларның кыланмышлары, үз-үзләрен тотышлары, уй-хыяллары, шатлык-кайгылары, мутлыклары-шуклыклары бер үк. Бала кайда да – бала, балалар шагыйре кайда да балалар шагыйре булып кала икән...», – дип язды шагыйрь үзенең бер истәлегендә [Миңнуллин, 2004:223].

Фикеребезне, автор тарафыннан шигырьләре яратып тәрҗемә ителгән Агния Барто иҗаты белән дәвам итик.

Аерым галимнәр раславынча, Агния Бартоның формалашуда В.В. Маяковскийның йогынтысы зур була. Бу тәэсир аның әсәрләрендә сатирик юнәлгәнлек, стилистик экспериментларга һәвәслек булу белән аңлатыла. Чөнки А. Барто бер шигырь кысаларында кинәт фикерне алыштыра («Ох, доска кончается, / Сейчас я упаду»), кайчагында каламбурлыкны алгы планга куя («мне когда» – «некогда»; «Лида, мол» – «выдумал»), яки, көтелмәгән экспрессив рифмаларга мөрәҗәгать итә. (Форма ягыннан мондый эзләнүләр, еш кына, тәнкыйтьләнә дә!). Күрәсең, нәкъ менә шушы эзләнүләр, иҗатта аваздашлык Р. Миңнуллинның ихтибарын җәлеп итсә кирәк. А. Барто шигырьләрендә дә балалар образы сатирик һәм юмористик планда ачыла. Мисал итеп, «Әтинең чыкты ачуы» үрнәген китерергә мөмкин:

Алып кайттым мин «икеле» –

Андый хәл сезгә таныш.

Әтинең чыкты ачуы,

Тик чыгармады тавыш.

Бик борчый бу сөйләшмәү,

Юкка түгел бу дәшмәү! [Миңнуллин, 2007:301].

Шигъри әсәрне тәрҗемә итү – тәрҗемә эшчәнлегенең иң югары ноктасы. Бу вакытта тәрҗемәче икенче бер шагыйрьнең фикерен төгәл җиткерергә, әсәрнең милли үзенчәлекләрен тапшыра белергә һәм, еш кына, шигырь размераларын да сакларга тиеш. Чөнки әдәби текстны тәрҗемә итү процессында төрле мәдәниятләр – әсәр язылган телне йөртүче халыклар мәдәнияте һәм тәрҗемә итүченең милли әдәбияты һәм мәдәнияте, шәхесләр – оригинал әсәрнең авторы һәм тәрҗемәче шәхесе, аларның дөньяны күзаллавы, төрле традицияләр очраша. Шушы яссылыктан чыгып бәяләгән вакытта, алда мисал итеп китерелгән шигырьне тәрҗемә әсәре дип әйтү бәхәс тә тудырыр кебек. Чөнки балалар шигърияте өлкәсендә күпеллык тәҗрибәбез күрсәткәнчә, тел, образлылык, балалар өчен шигырьләрдәге ритм-рифма, шигырь төзелеше үзенчәлекләре һәр милли мирасның үзәк өлеше булып тора, һәм, нәтиҗәдә, башкалардан аерылып торучы этник – милли фикерләү дәрәҗәсе үзгәрәк булган халыкны аерып карау мөмкинлеге туа. Ә бу очракта без татар балалар поэзиясенә һәм Р. Миңнуллин иҗатына хас сыйфатлар белән очрашабыз. Ягъни, тәрҗемә эшчәнлегендә дә шагыйрьнең үз стиле, миллилек, халыкчанлык, иҗадилык өстенлек итә. Алга таба да без әлеге фикеребезне үстерергә, дәлилләргә тыршырбыз. Тагын шуны ассызыклап китү зарур, тәрҗемә әсәрләрен сайлап алуда Р. Миңнуллинның таләпчән зәвыгы чагыла: аларда идея-фикер төгәл, әдәп-әхлак мәсьәләләре югары дәрәҗәдә, һәм, шагыйрьнең үз иҗатына хас образлылык, шигырь төзелеше үзенчәлекләрен дә күрергә мөмкин. Мисал өчен, әрмән шагыйре Сильва Капутикяннан тәрҗемәдә «Рәсем» шигыре, байтак дәрәҗәдә Р. Миңнуллинның «Елмаючы бүреләр»ен хәтерләтә:

Ясадым мин нәни тычкан.

Ул почмакка кереп поскан.

Почмакка ул юкка поскан-

Янамый бит аңа дошман.

Әмма сизсәм урлашканын,

Мин аны тиз тыячакмын-

Каршысына ук олы бер

Песи ясап куячакмын! [Миңнуллин, 2007:335].

Аерым тикшеренүләр күрсәткәнчә, Р. Миңнуллинның балалар өчен үз иҗатында уен функция зур урын алып [Mingazova 2014:423]. Шигъри уен формасын – характер ачу чарасы, психологик халәтне бирү алымы, зурларның «гаделсез» карашларына каршы чыгу чарасы буларак та Р. Миңнуллин поэзиядә яратып куллана. Мондый үрнәкләр балаларга яңа төшенчәләр бирү һәм фикерләү сәләтен үстерү ягыннан да әһәмиятле. Фольклордагыча шигырьләрьдә бер үк сүзнең, яки, яңгырашы белән охшаш сүзләрнең берничә тапкыр янәшә кабатлануы да отышлы. Мондый алым, әлбәттә, нәниләргә әсәрләрнең эчтәлеген тизрәк аңлау, яңа сүзләрне җиңелрәк үзләштерү мөмкинлеген ача. Әлеге алымны автор тәрҗемә эшчәнлегендә дә уңышлы файдалана:

Кәбестә татлы-татлы,

Чөнки ул катла-катлы [Миңнуллин, 2007:347. Юозас Некрошюс. «Куяннар төш күрә»].

Яки,

– Әйдәле ит турагычка!

Әйдәле ит турагычка!

Туп-туры кит турагычка!

Туп-туры җит турагычка!

Туп-туры... марш! [Миңнуллин, 2007:336. Михаил Яснов. «Кухняда. Әнигә булышканда»].

Балалар психологиясе белән бәйле аерым специфик үзенчәлекләрне Р. Миңнуллин тәрҗемә эшчәнлегендә дә онытмый: балалар язучысы үзенең укучысы белән уенга керешкән очракта куйган максатына тизрәк һәм нәтиҗәлерәк ирешә, уенчыл лирик әсәрләр тизрәк ятлана, ачышлар да кызыклырак, көтелмәгәнчәрәк ясала:

Әбинең күзе күрми,

Җеп, ахры, шуңа керми.

Әбием шуны белми.

Энәсен миңа бирми [Миңнуллин, 2007:334. "Энә" Надар Думбадзе].

Р. Миңнуллин шигырьләрен махсус рәвештә уенга әйләндерергә омтыла. Кече һәм урта яшьтәге балалар өчен ул, мәсәлән, шигъри формада сүзләр белән уенны тәшкил итә: кыска яки озын шигъри юллар, ритм, рифма, бер үк яки охшаш авазларны кабатлау, антоним, омоним, синоним сүзләрне кулланып язу һ.б. Тәрҗемә юнәлешендә дә шагыйрь бу алымны бик теләп куллана.

Мәглүм, сорау-җавап формасындагы лирик әсәрләр, беренче чиратта, шатлык, куаныч, аптырау, борчылу, шаккату, кызыксыну кебек хис-кичерешләр уятуга йөз тотып языла. Моңа өстәп, андый лирик әсәрләрдә сюжет сызыгы уйланылган булуы, билегеле бер мәгълүмат җиткерү максаты белән язылуы – аның халык авыз иҗаты һәм балалар шигърияте кануннарына нигезләнүе белүе белән аңлатыла [Mingazova, 2014:416]. Р. Миңнуллин тәрҗемәләрендә мондый үрнәкләр дә еш очрый. Удмурд язучысы Вячеслав Ар-Сергиның «Балалар санамышы» шигырендә балалар соравы, сөйләме аша зур проблемалар күтәрелгән:

- Әни, әни, әллә без

Бик әйбәт түгелбезме?-

Нигә яратмый бу байлар

Безнең үз телебезне?

- Әни, әни, шәһәрләрдә

Көләләр нигә бездән?-

Йөзебездән, киемебездән,

Сөйләшкән телебездән... [Миңнуллин 2007:310].

Әлеге шигъри юллар аша Р. Миңнуллин балаларны җәмгыятьтәге катлаулы проблемалар белән таныштыра. Кыю әйтелгән аерым фикерләр, татар җәмгыяте өчен бүген аеруча актуаль.

Тәрҗемәләрнең тагын бер отышлы ягы шунда: Р. Миңнуллин баланы табигатьнең бер өлеше итеп карый, образлар, еш кына, табигать балалары. Бу хәл аңлашыла да, чөнки Р. Миңнуллин тәрҗемә өчен үзенә якын, балаларга кызыклы темаларга иҗат ителгән шигырьләрне сайлап ала. Табигать, аны чолгап алган тирәлек, туган авыл, хайваннар томышы, үсемлек-агачларның үсеш-үзгәреше Р. Миңнуллинның үз иҗатына да, фольклорның күпгасырлар дәвамында барган үсеш эволюциясе нәтиҗәсендә килеп керә. Шунлыктан, Ояр Вациетисның «Әкәмәт әкәм-төкәм», «Кояш тәме», «Җиләк турында җыр», Григоре Виеруның «Әйтче кояш», «Дуңгыз баласы», «Болыт белән салават

күпере», Сергей Михалковның «Кызылтүш», Юозас Некрошюсның «Куяннар төш күрә», «Карга бичара», «Скрипкачы сикерткә», Җолдас Сәетназаровның «Каен төбендә», Ирэна Сергеевна «Аккошлар», Максим Цагараевның «Кояш» һ.б. шигырьләренең тәрҗемәләрендә Р. Миңнуллин баланы табигатьнең аерылгысыз бер өлеше итеп тасвирлауга ирешә.

Балкый җиде төсе дә

Ерактан ук күренеп.

Җидесе дә бик матур!

Эх, алырга үрелеп [Миңнуллин, 2007:379. Мозаффар Әлимбаев. «Салават күпере»].

Яки,

Юл буйлап чаба каеннар,

Әй чаба безгә табан.

Кая ашыга соң алар?

Арыганнардыр тәмам [Миңнуллин, 2007:363. Раиса Сарби. «Каеннар – юртаклар»].

Бу уңайдан, осетин шагыйре Александр Цурукаевның «Көзге урман» шигыренә тукталып үтү урынлы булыр. Әлеге шигырьне Р. Миңнуллин шулкадәр табигый тәрҗемә иткән ки, ул шагыйрьнең үз әсәре буларак кабул ителә. Иң кызыгы, лирик әсәрдә текст асты мәгънәсе нәкъ менә табигать картинасына салынган:

Көзге урман

Күземә тау түбәсеннән

Ап-ак кар карап тора...

Бушап калган агачларда

Тирбәлүче оялар...

Сандугач ояларына

Инде карга оялар [Миңнуллин, 2007:305].

Р. Миңнуллинның тәрҗемә эшчәнлеге шигырьләрне бер телдән икенче телгә сүзгә-сүз, коры тәрҗемә итүгә генә кайтып калмый. Аның тәрҗемәләре милли хисләр белән сугарылган, татар халкының рухи кыйммәтләре чагылыш алган. Бу хәл Р. Миңнуллин тарафыннан туган телнең тел-сурәтләү чараларын киң һәм урынлы куллана белүеннән килә. Автор тарафыннан бик яратып тәрҗемә ителгән автор – Душан Джуришичтан тагын бер әсәр – «Гыйнвар җиле» мисалы белән фикеребезне дәлиллик:

Бигрәк салкын, дип сызгыра

Гыйнвар җиле, -

Калтырана кышкы җилнең

Бөтен җире.

Калтырана, әйтерсең лә

Тота бизгәк.

Өйгә кереп җылынырга

Кирәк тизрәк [Миңнуллин, 2007:135].

Ягъни, фикеребезне тагын да үстерсәк, ул бу очракта түбәндәгечә яңгырар иде: пейзаж лирикасы – билгеле бер табигать күренешен, шагыйрь күңелендә тойгы, язу теләге тудырган сурәтне күчереп кую, сөйләп бирү генә түгел, балаларга таныш дөньяны, әйләнә-тирәне башкача күрү, бәяләү дә.

Чуашның мәгълүм шагыйре Юрий Семендернең «Яңгыр явар алдыннан» исемле шигырь тәрҗемәсе дә шактый кызыклы. [д], [р], [т] авазларының еш кабатлануы үзенә бертөрле яңгыраш тудыра:

Дөбер-дөбер

Дөберди –

Бөтен дөня

Дерелди.

Түшәм ишелер кебек

Түшәм тишелер кебек [Миңнуллин, 2007:369].

Мондый төр лирик әсәрләрне уку дәвамында бала телнең яңгырашына игътибар итә, сүз ритмын ишетергә омтыла, кызыксына. Шигырьдәге гадәти күренеш-тасвирның эстетик тәэсир итү көче дә зур. «Д» авазының күп тапкырлар кабатлануы күк күкрәү, яшен яшнәүгә иярүне күрсәтә. Нәтиҗәдә шагыйрь кыска гына вакыт аралыгында тулы бер манзара тудыруга ирешә. Бер үк авазларны кабатлау шигырьнең музыкаль яңгырашын, аһәңен дә тәэмин итә.

Балалар шигърияте ул – гадәти тормыш күренешләрен, гадәти әйберләрне, әйләнә-тирәлекне «поэзияләштерү» аңа аерым мәгънә һәм матурлык бирү, әкияти шартлылык, әкияти әверелүләр, әлбәттә. Алдарак инде билгеләп үтелгәнчә, татар халык авыз иҗатына битараф булмаган шагыйрь, мөмкинлек чыкканда тәрҗемәләрдә дә әкияти алымнарга мөрәҗәгать итәргә тырыша:

Малайлар бер көн көтте...

Алар ике көн көтте...

Өченче көн дигәндә...

Бер җимеш борын төртте [Миңнуллин, 2004: 103. Леон Бриедис. «Алмагачта ни үсә?»].

Расланган хакыйкать, үсеш дәвәменда һәр этносның яшь вәкиле үзе яшәгән тирәлек – конкрет җәмыяьтнең тарихи хәтерен, традицияләрен, гореф-гадәтләр, рухи кыйммәтләрен, яшәү нормаларын үзләштерә. Әлеге процесста туган тел, аның таләпләре дә өйрәнелә. Нәкъ менә шуңа күрә һәр халык вәкиле балалар өчен иҗатында үз теленең матурлыгын, музыкальлеген җырлый:

Җырламый бүген җырчы кош.

Бәлки бик аргандыр ул.

Юк ла, безнең сөйләшкәнне

Тыңлап тын калгандыр ул.

Әгәр дә бик кирәк булса

Иң моңлы сүз, матур сүз,

Безнең туган телебездән

Алсын ул кош, әйтерсез! [Миңнуллин, 2007:329. Григоре Виеру. «Туган тел»].

Григоре Виеруның, молдаван шагыйренең, туган телен яратуы һәм хөрмәт хисләрен татар шагыйре уңышлы бирә алган. Биредә «моң» сүзен тәрҗемәче махсус кулланган дигән уй туа. Чөнки бу, татар милләтенә генә хас сүз, «моң» концепты үз эченә бик күп мәгънәләрне салган. Һәм ул һәр милләт вәкиле өчен туган телнең бөеклеген аңларга ярдәм итә.

Р. Миңнуллинның барлык тәрҗемәләре, нигездә, ирекле тәрҗемәләр. Аларны шартлы рәвештә ике төргә бүлеп булыр иде, оригиналдагыча, һәм, оригиналны беркадәр үзгәртеп эшләгән тәрҗемәләр. Аларда шагыйрьнең үз табышлары, үз карашлары да өлешчә урын алган. Тәрҗемә бит төрле вариантларда булырга мөмкин. Әсәр укучының күңеленә үтеп керсә, аны тәэсирләндерә алса, димәк бу – уңышлы тәрҗемә. Тәрҗемәче, башка әдәбият һәм мәдәниятны үз укучысы өчен төрле яссылыктан чыгып яктыртырга, һәм кирәк дип санаса, мәгънә төсмерләрен киңәйтергә дә мөмкин. «Туган тел» шигырендә дә без бу очрак белән очраштык.

Агагельды Алланазаровның «Көтү каршылаганда» шигыре шаян рухта тәрҗемә ителгән. Кечкенә геройның санарга өйрәнүе – әмма көтүдән кайтып килүче малларның саны уннан артса, баланың санда буталуы, кызыклы да, мавыктыргыч та итеп тасвирланган:

Малкайлар,

Бераз көтегез инде.

Әбиемнән сорап килим –

Сабыр итегез инде [Миңнуллин, 2007: 292].

Р. Миңнуллинның тәрҗемә шигырьләре җиңел тел белән язылган. Моның сере – шагыйрьнең нәниләр психологиясен яхшы белүендә һәм табигать биргән таланты өстенә, тырышлыгында да. Чөнки автор һәрвакыт эзләнә, уйлана. Геройларын ачу өчен яңа формалар эзли. Аның үз иҗатында да бераз мактанчыграк, тыңлаусызрак, әмма эчкерсез, садә геройлар күп. Бәлки, шуңа күрә тәрҗемә эшендә дә ул мондый геройларга еш мөрәҗәгать итә.

Инде алдарак искәртеп үттек, тәрҗемәдәге төп уңыш текстның чыганак-нөсхәгә туры килүе белән билгеләнә. Бу нисбәттән, Т.Г. Никитченко тәрҗемәчегә бәйле түбәндәге таләпләрне аерым билгеләр итеп күрсәтә: а) социаль сыйфатлар; б) эчке шәхси сыйфатлар; в) филологик белем, осталык, күнекмәләр; г) оригинал язма авторы шәхесе һәм тәрҗемәченең туры килү-килмәве (якынлык яки охшашлык, шәхесләрнең нык аерылып торуы) [Никитченко, 2000:11]. Бу уңайдан тагын бер тапкыр Р Миңнуллинның чит халык вәкилләре белән шәхси дуслыгын, рух һәм уй-теләкләр берлеген аеруча билгеләп китү урынлы булыр.

Р. Миңнуллин тәрҗемә эшчәнлегендә еш кына татар фольклорына – фразеологизмнарга, мәкаль-әйтемнәргә, халык телендә йөргән сүзләргә, тезмәләргә дә мөрәҗәгать итә. Ул бер яктан, сәнгатьлелек, тәэсир итү чарасы буларак кулланылса, икенче яктан, укучы өчен фикерне тирән төшенү мөмкинлеген ача. Шагыйрь укучысын әсәрне кабул итәргә дә әзерли. Мәгълүм, балалар турыдан-туры тәрҗемәне кабул итәргә әзер дә булмаска мөмкин. Чөнки ул тәрҗемә ителгән халык даирәсен белми, андагыча тәрбияләнмәгән. Еш кына, башка халыклар өчен генә хас гыйбарәләр, ирония, читләтеп әйтүләр дә аның өчен аңлаешсыз, мәгънәсез сүзләр тезмәсе генә булырга мөмкин. «Кеше ышанмаслык сүзне, Сөйләмә, чын булса да!», «Диңгез аңа тубыктан» кебек фольклор

үрнәкләре, бердән, лирик әсәргә мәкальләрдәгечә кыска, төгәл нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Икенчедән, шагыйрь укучыларны татар телендәге мәкаль-әйтемнәр, фразеологизмнар һ.б. таныштыра.

Әйе, әйе, ул чын моряк,

Диңгез аңа тубыктан.

Шаулы диңгездән тамчы да

Курыкмый ул шунлыктан [Миңнуллин, 2004: 35. Душан Джуришич. «Минем этием– моряк»].

«Китми аның исе дә», «котын алган» кебек фразеологик әйтелмәләр дә шигырь төзелешен, эчтәлеген үзенчәлекле итә.

Шулай итеп, Р. Миңнуллин тарафыннан тәрҗемә өчен сайланган әсәрләр образларның индивидуальлеген ассызыклый, этик, әхлакый нормаларны пропагандалый, укучыны үз артыннан ияртә. Аларның күпчелегенә ирекле тәрҗемә ясалып, милли җирлегебезгә күчерелә, милли колорит белән баетыла. Бу геройларның исемнәрендә дә, аларның сөйләмендә дә, тирә-якны тасвирлаганда да сизелеп тора. Шуның белән беррәттән, башка әдәбиятлар стиле дә беркадәр саклана.

Димәк, әйтелгәннәрдән чыгып фикер йөртсәк, һәр милләтнең балалар өчен әдәбияты бала акылы, танып белүе формалашуының аерылгысыз бер өлеше генә булып калмый, бәлки, ул үзенчәлекле милли-мәдәни күренеш тә. Мәгълүм ки, гасырлар дәвамында милли идеаллар, әхлакь принцилары аша милли әдәбиятлар формалаша. Төрле тарихи этапларда, географик шартлар белән дә бәйле, миллилек, гореф-гадәтләр, традицияләр кебек төшенчәләр ярдәмендә балалар күңеленә тәэсир итәрдәй нигезле психологик алымнар, чаралар туа һәм алар яшь буында милли үзаң формалашуда нигез булып тора. Мондый шартларда, әлбәттә, бу билгеләр тәрҗемә әсәрләренең үзәгендә булырга тиеш кебек. Әмма, Р. Миңнуллинның уңышлы тәрҗемәләре аша балачак иле, сабыйларның дөньяны танып белүе, төрле милләт балаларының уйлары һәм теләкләре бердәй дәрәҗәдә охшаш һәм тәңгәл икәнлеге отышлы ачыла. Ягъни, Р. Миңнуллин тәрҗемә эшчәнлегендә татар теленең бөтен эчке мөмкинлекләреннән дә файдаланып эш итәргә омтыла дип нәтиҗә ясарга тулы нигез бар.

Е.В. Бреус фикеренчә, тәрҗемә өлкәсе чиксез рәвештә үз-үзен үзгәртеп торырга сәләтле һәм өч субстанция – Кеше, Текст һәм Вакытка нигезләнә. Шәхес текстка карата ике мөнәсәбәттә чыгыш ясый: Автор/Укучы, ә тәрҗемәгә бәйле өч мөнәсәбәттә чыгыш ясый: Автор/Тәрҗемәче/Укучы [Бреус, 2002: 23].

Моннан түбәндәге мөнәсәбәт ачыклана: тәрҗемәчедә никадәр иҗади энергия югары булса, шулкадәр ул тәрҗемә иткән материалда шәхси идеяләре чагылыш табачак. Әлеге терияне истә тоткан хәлдә, өйрәнелү объекты булган шәхес иҗатына күчсәк, Р. Миңнуллинның барлык тәрҗемәләре – нигездә ирекле тәрҗемәләр. Аларны шартлы рәвештә ике төргә бүлеп була: оригиналга якын һәм оригиналдан ераклашкан тәрҗемәләр. Беренчеләрендә текстлардан читкә китми генә, әмма киңәйтеп тәрҗемә итү очраса, икенчеләренең характеры төрлечә. Алар арасында шагыйрьнең үз табыш-строфалары кушылган өлешчә тәрҗемәләр байтак, тәрҗемәләрдә оригиналның аерым юллары, татар халкы тормышына, рухына, яки, әдипнең үз иҗади рухына туры килмәве нәтиҗәсендә, төшерелеп калдырылганнар. Ягъни, Е.В. Бреус теориясенә таянсак, Р. Миңнуллинда иҗади энергия югары булу сәбәпле, тәрҗемә ителгән материалда шәхси идеяләре иркен чагылыш тапкан дип нәтиҗә ясарга җирлек зур.

**Әдәбият исемлеге**


GALIMULLIN, F. G. - GALIMULLINA, A. F. - MINGAZOVA, L. I. (2014). The development of the literatures of the people of the Volga region in multi-ethnic Russia. *Journal of Language and Literature* 5 (3), 248-252. DOI: 10.7813/jll.2014/5-3/42.

GALIMULLIN, F. G. - GALIMULLINA, A. F. - MINGAZOVA, L. I. (2016). Common roots, common spirituality: literary relationships of the tatar and azerbaijani literature in the context of the dialogue of cultures. *The Social Sciences*, Year: 2016 | Volume: 11 | Issue: 16 | Page No.: 3940-3945.

MINGAZOVA, L. - SULTEEV, R. (2014). Tatar and English Children's Folklore Education in Folk Traditions. *Western Folklore*, 73.4 (Fall): 410-431.

БАРХУДАРОВ, Л. С. (1975). *Язык и перевод.* Moskva.

БРЕУС, Е. В. (2002). Перевод как акт межъязыковой коммуникации. *Взаимодействие языков в процессе перевода. как фактор межкультурной коммуникации.* Краснодар, С. 21-26.

ЗАҺИДУЛЛИНА, Д. (2000). *Әдәбият кануннары һәм заман.* Казан: Татар. кит. нәшр., 272 б.

ХАБУТДИНОВА, М. - МУХАМЕТШИНА, Р. (2017). Славомир Мрожек на татарской сцене: метаморфозы польского текста. *Przeglad wschodnioeuropejski*, VIII /2. С. 309-318.

МИҢНУЛЛИН, Р. (2004). *Дуслашасым килә. Миңнуллин Р. Сайланма әсәрләр: Балалар өчен шигырьләр, әдәби тәнкыйть, иҗат портретлары, рецензияләр.* Т.2., Казан: Мәгариф.

МИҢНУЛЛИН Р. М. (2007). *Әсәрләр. Җиде томда. Т.7: мәкаләләр, юлъязмалар, рецензияләр, әңгәмәләр.* Казан: Татар. кит. нәшр.

НИКИТЧЕНКО, Т. Г. (2000). *Субъективный фактор в художественном тексте: лингвистический и психологический аспекты (на материале перевода).* Автореф. дис. канд. филол. наук, Краснодар.

ЮЗЕЕВ, И. (1978). Безнең сафка. Роберт Миңнуллин. *Казан утлары*, № 3, Б. 186.

ЮСУПОВ, Р. (1975). *Тәрҗемә мәсьәләләре*. Казан: Татар. кит. нәшр.